# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы
Айбаш авыл җирлеге Кодаш торак пунктында
гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

7 ноябрь 2020 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2020 елның 07 ноябрендә 10 сәгать 00 минутта уздырылган “Сез 2021 елда Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Айбаш авыл җирлеге Кодаш авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?” дигән мәсьәлә буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде:

а) авыл эчендәге юлларны һәм тротуарларны карап тоту һәм ремонтлау (вак таш салу, асфальт түшәк җәю)

б) су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу челтәрләрен төзү һәм ремонтлау (торак пунктта янгынга каршы җайланмалар урнаштыру)

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 50 (илле) кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 35 кеше, бу 70%ны тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар түбәндәгечә бүленде:

«РИЗА» позициясе өчен гражданнар җыенында 32 (утыз ике) катнашучы тавыш бирде;

«КАРШЫ» позициясе өчен җыенда катнашучы 3 (өч) кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, гражданнар җыены түбәндәгечә хәл итте:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Айбаш авыл җирлеге Кодаш торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. 2021 елда үзара салым акчасын яшәү урыны буенча теркәлгән һәм Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Кодаш авыл җирлеге территориясендә даими яшәүче һәр балигъ булган һәр кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә кертергә.

3. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен юнәлтергә:

а) авыл эчендәге юлларны һәм тротуарларны карап тоту һәм ремонтлау (вак таш салу, асфальт түшәк җәю)

б) су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу челтәрләрен төзү һәм ремонтлау (торак пунктта янгынга каршы җайланмалар урнаштыру)

4. Әлеге карарны мәгълүмати стендларда, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында авыл җирлекләре бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлар регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче Р.Р. Сафиуллин